**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

---

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

2014 елның 17 феврале № К-26/03-03

Казан шәһәре

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турындагы нигезләмәне раслау хакында

"Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында" 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль закон, "Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында" Россия Федерациясе Президентының 01.02.2005 № 112 Указы нигезендә б о е р ы к б и р ә м:

1. Кушымта итеп бирелүче Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турындагы нигезләмәне расларга.
2. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының "Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурслар уздыру турында" 17.08.2006 № К-118/03-02 боерыгы үз көчен югалткан дип танырга.
3. Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының бердәм банкы бүлеге (Аверьянова Э.М.) әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алырга тиеш.
4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге башлыгы М.Х. Хәсәновка йөкләргә.

Министр Л.Ю. Глухова

Татарстан Республикасы
Юстиция министрлыгының
17.02.2014 № К-26/03-03
боерыгына кушымта

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турындагы

# НИГЕЗЛӘМӘ

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә белән Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру буенча конкурс комиссиясе (алга таба – конкурс комиссиясе) составы, эш сроклары һәм эш тәртибе, шулай ук Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру методикасы билгеләнә.

1.2. Нигезләмә Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру тәртибен һәм шартларын билгели. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс (алга таба – конкурс) Россия Федерациясе гражданнарының дәүләт хезмәтенә бертигез дәрәҗәдә керә алуы буенча конституциячел хокукын, шулай ук дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба – граждан хезмәткәрләре) конкурс нигезендә вазыйфаи үсү хокукын тәэмин итә.

1.3. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында (алга таба – Министрлык) конкурс "Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында" 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – Федераль закон) 22 статьясы һәм "Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында" Россия Федерациясе Президентының 01.02.2005 № 112 Указы (алга таба – Указ) нигезендә уздырыла.

Конкурс граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә дәгъвачыларның һөнәри дәрәҗәсен, аларның дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына карата билгеләнгән квалификацион таләпләргә туры килүен бәяләүдән гыйбарәт.

1.4. Министрлыкта биләве конкурс нигезендә уздырыла торган граждан хезмәте вазыйфасы булганда, конкурс Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы юстиция министры (алга таба – Министр) карары буенча игълан ителә.

1.5. Конкурс уздыру турындагы карар структур бүлекчә җитәкчесе тарафыннан әзерләнгән язмача исбатланган гариза нигезендә Министр тарафыннан кабул ителә.

Гаризада, конкурс игълан итү турындагы тәкъдим белән бергә, дәүләт граждан хезмәте вазыйфасының (алга таба – граждан хезмәте вазыйфасы) атамасы һәм, вазыйфаи бурычларның үзенчәлеген исәпкә алып, шушы вазыйфаны биләүгә дәгъвачыга карата таләпләр (әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымта) булырга тиеш.

1.6. Министрлыкта конкурс түбәндәге очракларда уздырылмый:

а) Министрлыкта “җитәкчеләр” һәм “ярдәмчеләр (киңәшчеләр)” категорияләренең граждан хезмәте вәкаләтләрен билгеле бер срокка биләнә торган вазыйфаларына билгеләп куйганда;

б) сроклы хезмәт контракты төзегәндә;

в) граждан хезмәткәрен Федераль законның 28 статьясындагы 2 өлешендә, 31 статьясының 1 өлешендә һәм 60.1 статьясының 9 өлешендә каралган бүтән вазыйфага билгеләп куйганда;

г) граждан хезмәтендә кадрлар резервына кертелгән граждан хезмәткәре (граждан) граждан хезмәте вазыйфасына билгеләп куелганда;

д) граждан хезмәтенең кече вазыйфалары төркеменә кертелгәннәр граждан хезмәте вазыйфасына билгеләп куелганда.

1.7. Конкурс вазыйфаи бурычларны башкарулары дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрне куллануга бәйле граждан хезмәтенең аерым вазыйфалары буенча Министрлык боерыгы белән расланган вазыйфалар исемлеге буенча уздырылмаска да мөмкин.

1.8. Конкурс түбәндәге максатларда уздырыла:

Россия Федерациясе гражданнарының сәләтләре һәм һөнәри әзерлекләре нигезендә дәүләт граждан хезмәтенә бертигез дәрәҗәдә керә алулары хокукларын, шулай ук дәүләт граждан хезмәткәрләренең конкурс нигезендә вазыйфаи үсүгә хокукын тәэмин итү;

федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары белән билгеләнгән таләпләргә туры килүче һәм конкурста катнашуга кертелгән кандидатларның гомуми санынннан граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен иң туры килә торган кандидатларны сайлап алу;

Министрлыкның кадрлар резервын булдыру.

1.9. Конкурслар уздырганда хәл ителә торган бурычлар:

барлык кандидатлар өчен алар конкурс биремнәрен һәм процедураларын үтәгәндә тигез шартлар тудыру;

һөнәри әһәмиятле объектив критерийлар нигезендә кандидатларны бәяләү;

конкурсларда катнашучылар арасыннан конкурслар процедуралары барышында объектив һәм нигезле күрсәткечләрне чагыштыру юлы белән граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфалары таләпләренә туры килүче затларны билгеләү.

## II. Конкурс комиссиясен булдыру һәм аның эш тәртибе

2.1. Министрлыкта конкурс уздыру өчен Министр боерыгы белән конкурс комиссиясе төзелә.

2.2. Конкурс комиссиясе комиссия рәисеннән, рәисе урынбасарыннан, секретареннан һәм әгъзаларыннан тора.

2.2.1. “Җитәкчеләр” категориясе граждан хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру өчен конкурс комиссиясен вәкаләтләре срогы билгеләнмичә Министр җитәкли.

2.2.2. Граждан хезмәтенең бүтән вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурслар уздыру өчен Министр боерыгы белән граждан хезмәтенең төрле категорияләре һәм төркемнәре өчен берничә конкурс комиссиясе төзелергә мөмкин.

2.3. Комиссия рәисе конкурс комиссиясе эшчәнлегенә җитәкчелек итә, утырыш уздыру датасын билгели һәм аның көн тәртибен раслый, комиссия утырышларында рәислек итә һәм тиешле документларга имза сала. Комиссия рәисе булмаганда, аның хокукларын һәм бурычларын конкурс комиссиясе рәисе урынбасары үти.

Конкурс комиссиясе рәисе тарафыннан конкурс процедураларын әзерләү һәм уздыру буенча эш төркеме составын раслый.

Конкурс комиссиясе секретаре комиссия эшен тәэмин итә (гаризаларны теркәү, кабул итү, эшләрне формалаштыру, комиссия беркетмәләрен алып бару).

2.4. Конкурс комиссиясе составына Министр урынбасарлары, эшләр белән идарәче, Министрлык бүлекләре җитәкчеләре: кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының бердәм банкы бүлеге, финанс бүлеге, җәмәгать судьялары эшчәнлеген оештыру-хокукый тәэмин итү бүлеге, хокукый мәгълүматлаштыру һәм компьютер системалары бүлеге, Министрлыкның граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздырыла торган структур бүлекчәсе җитәкчесе яисә җитәкчесе урынбасары, Министрлыкның югары квалификацияле хезмәткәрләре, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты вәкиле, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет вәкиле, шулай ук фәнни һәм мәгариф учреждениеләре, Министрлык гарызнамәсе буенча бәйсез экспертлар – экспертларның персональ белешмәләрен күрсәтмичә, граждан хезмәте мәсьәләләре белән бәйле белгечләр сыйфатында Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан чакырыла торган башка оешмалар вәкилләре керә. Бу вәкилләрнең һәм бәйсез экспертларның гомуми саны конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми саныннан кимендә дүрттән берен тәшкил итәргә тиеш.

2.5. Граждан хезмәтенең вазыйфаи бурычларын үтәве дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрне куллануга бәйле граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру өчен конкурс комиссиясе составы дәүләт сере турында Россия Федерациясе законнары нигезләмәләрен исәпкә алып булдырыла.

2.6. Конкурс комиссиясе составы конкурс комиссиясе кабул итә торган карарга йогынты ясарга мөмкин булган мәнфәгатьләр конфликтлары булмаслык итеп формалаштырыла.

2.7. Конкурс комиссиясе утырышы Министрлыкның граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) барлык кирәкле документларны билгеләнгән срокта тапшырган кимендә ике кандидат булганда уздырыла. Утырышларны Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче комиссия әгъзалары катнашында гына уздыру рөхсәт ителми.

2.8. Конкурс комиссиясе түбәндәге карарларны кабул итә:

конкурс уздыру шартларын регламентлаучы документларны, методик һәм конкурс уздыру өчен кирәкле башка материалларны раслау турында;

конкурс уздыру план-графигын раслау турында;

конкурска йомгак ясау турында;

конкурс процедураларын уздыру нәтиҗәләре буенча төзелгән рейтингта беренче урынны алган кандидатларны конкурста җиңүчеләр дип тану турында;

Татарстан Республикасы граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләү өчен Министрлыкта кадрлар резервына тәкъдим ителгән кандидатлар исемлекләрен формалаштыру турында.

2.9. Конкурс уздыру нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе карары ачык тавыш бирү юлы белән утырышта катнашучы комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, конкурс комиссиясе рәисе тавышы хәлиткеч була. Конкурс комиссиясенең теләсә кайсы әгъзасы, кабул ителгән карар белән риза булмаганда аерым фикерен белдерә ала, бу фикер комиссия утырышы беркетмәсендә билгеләп куела һәм конкурс комиссиясе әгъзасы имзасы белән беркетелә.

2.10. Конкурс комиссиясе карары кандидат булмаганда кабул ителә һәм аны граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына билгеләп кую яисә кадрлар резервына кертү йә баш тарту өчен нигез була.

2.11. Конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан кабул ителә торган карарлар (комиссиянең тавыш бирү нәтиҗәләре) конкурс комиссиясе беркетмәсе рәвешендә (әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымта) рәсмиләштерелә, аңа комиссия рәисе, рәисе урынбасары, секретаре һәм утырышта катнашкан комиссия әгъзалары имза сала.

2.12. Конкурс процедурасын эшләү һәм әзерләү буенча эш документлары эчтәлеге, сораулар исемлеге һәм конкурс биремнәре темалары конкурс тәмамланганчы хезмәттә файдалану мәгълүматы була.

2.13. Конкурсны турыдан-туры оештыруны һәм тәэмин итүне, конкурс комиссиясе эшен Министрлыкның кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге башкара.

## III. Конкурста катнашучылар

3.1. Конкурста катнашуга граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) кандидатларга карата тиешле таләпләргә туры килә торган гражданнар (алга таба - кандидатлар) кертелә.

Министрлыкта граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) кандидатларга карата таләпләр (әлеге Нигезләмәгә 3 нче кушымта) һәм Министрлыкта граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) кандидатлар тапшыра торган документлар һәм материаллар (әлеге Нигезләмәгә 4 нче кушымта) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен регламентлаучы норматив хокукый актлары нигезендә билгеләнә.

3.2. Конкурста катнашу өчен документлар кандидатлар тарафыннан Министрлыкка “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең рәсми порталындагы Татарстан Республикасы Юстиция

министрлыгы рәсми сайтында (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты) конкурс уздыру турында мәгълүмати хәбәр урнаштырылган көннән 21 көн эчендә тапшырыла.

3.3. Документларны вакытында тапшырмау, аларны тулы булмаган күләмдә яисә рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру аларны кабул итүдән гражданның бу гамәленә карата баш тарту өчен нигез була.

IV. Конкурс уздыру методикасы

4.1. Конкурс уздырганда кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү методларына нигезләнгән, федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына каршы килми торган конкурс биремнәре һәм процедуралары кулланыла.

4.2. Кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү критерийлары Министрлыкның граждан хезмәте вазыйфаларына билгеләнә торган таләпләр нигезендә эшләнә.

Конкурста катнашучыларны бәяләү критерийларының якынча исемлеге һәм кыскача тасвирламасы әлеге Нигезләмәгә 5 нче кушымтада китерелә.

Конкурс уздырыла торган вазыйфаларның төркеменә һәм категориясенә бәйле рәвештә катнашучыларны бәяләү критерийлары үзгәртелергә дә мөмкин.

4.3. Кандидатларны чагыштыру һәм сайлап алу аларның конкурс биремнәрен үтәү һәм конкурс процедураларын узу нәтиҗәләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

Нәтиҗәләр баллары (рейтинг) рангланган кандидатлар исемлеге рәвешендә тапшырыла.

4.4. Конкурс ике этапта уздырыла.

4.4.1. Беренче этапта Министрлык үзенең рәсми сайтында конкурста катнашу өчен документлар кабул итү турында мәгълүмати хәбәр урнаштыра.

Конкурс уздыру турында урнаштырылган мәгълүмати хәбәрдә граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасының (кадрлар резервы булдырыла торган вазыйфаның) атамасы, шушы вазыйфаны биләүгә дәгъвачыга карата белдерелә торган таләпләр, граждан хезмәтен узу шартлары, Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләгә конкурс турында Указ белән расланган Нигезләмәнең 7 пункты нигезендә тапшырылырга тиешле документларны кабул итү урыны һәм вакыты, әлеге документларны кабул итү вакытның узу срогы, конкурсны уздыру урыны һәм тәртибе, башка мәгълүмати материаллар күрсәтелә.

Конкурсның беренче этабы конкурс уздыру турында Министрлыкның рәсми сайтында мәгълүмати хәбәр урнаштырылган көннән башлана һәм кимендә 21 көннән соң тәмамлана.

4.4.2. Граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) кандидатлар тарафыннан тапшырылган документларны тикшергәннән, Министрлыкның кадрлар резервына керткәннән соң кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге документларны кабул итү тәмамланганнан көннән җиде көн эчендә Министрга гражданнарны (граждан хезмәткәрләрен) конкурста катнашуга кертү

турында карар кабул итү өчен йә конкурста катнаштырудан дәлилләнгән баш тарту өчен тәкъдим кертә.

Кандидатларның тикшерелгән документлары һәм кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге тәкъдиме конкурсның икенче этабын уздыру турында карар кабул итү өчен Министрга тапшырыла.

4.4.3. Тикшерү барышында федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актлары нигезендә гражданның граждан хезмәтенә керүенә каршы булырлык хәлләр билгеләнгән очракта, аңа кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге конкурста катнаштырудан баш тарту сәбәпләре турында язма рәвештә хәбәр итә (әлеге Нигезләмәгә 6 нчы кушымта)

4.4.4. Вакантлы вазыйфа биләүгә конкурска кертелмәгән дәгъвачы Россия Федерациясе законнары нигезендә бу карарга карата шикаять беледерергә хокуклы.

4.4.5. Конкурсның беренче этабының тәмамлану шарты билгеләнгән таләпләргә туры килүче ике һәм аннан да күбрәк кандидат булудан гыйбарәт, бу киләчәктә кандидатларны сайлап алу мөмкинлеген тәэмин итә.

Кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге, конкурсның икенче этабы башланырга 15 көн кала, конкурс уздыру датасы, урыны һәм вакыты турында конкурста катнашуга кертелгән гражданнарга (граждан хезмәткәрләренә) СМС-хәбәр җибәрә.

4.4.6. Конкурсның икенче этабы, граждан хезмәте вазыйфаларының конкурслар игълан ителгән төркеменә һәм категориясенә карап, өч рәвештә уздырылырга мөмкин.

А. Граждан хезмәтенең өлкән вазыйфаларына конкурс уздырылганда икенче этап кандидатлар тапшырган документларны анализлаудан һәм структур бүлекчәләр җитәкчеләре белән индивидуаль әңгәмәләр уздырудан гыйбарәт була*.

Б. Граждан хезмәтенең әйдәүче вазыйфаларына конкурс уздырылганда икенче этапта түбәндәгеләр уздырыла:

кандидатлар тапшырган документларны анализлау;

кандидатларның һөнәри белемнәрен ачыклау максатында аналитик эшләрен бәяләү;

структур бүлекчәләр җитәкчеләре белән индивидуаль әңгәмәләр уздыру.

Аналитик эшне (рефератны) кандидатлар вакансияләренә конкурс уздырыла торган структур бүлекчәләрнең эшчәнлеге юнәлеше буенча әзерлиләр. Аналитик эшләрне (рефератларны) бәяләү өчен Министрлыкның кандидатларга тәкъдим ителгән аналитик эш (реферат) темасына бәйле өлкәдә эшләүче башка структур бүлекчәләр хезмәткәрләре дә җәлеп ителергә мөмкин.

Кандидатларны конкурсның икенче этабында бәяләгәндә вазыйфаларның әлеге төркеме өчен кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү методларына нигезләнгән, федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актларына каршы килми торган конкурс биремнәре һәм процедуралары кулланылырга мөмкин (компьютерда яисә бланкта тест уздыру).

---

* Әлеге этапта аларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү өчен өстәмә тест уздырылырга мөмкин (компьютерда яисә бланкта тест уздыру). .

В. Граждан хезмәтенең баш вазыйфаларына конкурс уздырылганда икенче этап кандидатлар тапшырган документларны анализлаудан, структур бүлекчәләрнең эшчәнлеге юнәлеше буенча аналитик эшләрне (рефератларны) бәяләүдән, шулай ук Министрлык җитәкчелеге белән индивидуаль әңгәмәләр нәтиҗәләреннән гыйбарәт була.

Вазыйфаларның әлеге төркеме өчен формальләштерелгән методикаларны (тестларны) үтәү нәтиҗәләрен анализлау нигезендә, шулай ук төркемнәрдәге дискуссияләр һәм махсус биремнәр барышында кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү уздырыла. Биремнәрнең характеры һәм кандидатларга тәкъдим ителә торган төркемнәрдәге дискуссияләрнең киләчәк һөнәри эшчәнлеккә бәйле темалары экспертлар тәкъдимнәре нигезендә эшләнә һәм конкурс комиссиясе тарафыннан раслана.

4.4.7. Кандидатларга тест сынаулары язма рәвештә уздырыла. Конкурс комиссиясе дәгъвачыларның тест сынаулары өчен сораулар исемлеген төзи, шулай ук дөрес булмаган җавапларның иң чик санын раслый. Дөрес булмаган җавапларның иң чик саны 25 проценттан артмаска тиеш.

Сораулар исемлеге гомуми танышу өчен мөмкин булырга тиеш. Тест сораулар исемлеге нигезендә төзелә һәм конкурста катнашучыларның түбәндәгеләрне белүләрен тикшерүне тәэмин итәргә тиеш:

Россия Федерациясе Конституциясен һәм Татарстан Республикасы Конституциясен;

федераль законнарны һәм Татарстан Республикасы законнарын;

дәүләт граждан хезмәте турында Россия Федерациясе законнарын һәм Татарстан Республикасы законнарын;

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы турында нигезләмәне;

граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасының вазыйфаи регламентын;

структур бүлекчәнең эшчәнлек юнәлеше буенча норматив хокукый актларны.

Тест сораулары 50дән артмаска тиеш.

Дөрес сораулар саны тигез булганда катнашучыларга, җавапларга вакытны чикләп, өстәмә тестлар бирелә.

4.4.8. Кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләгәндә конкурс комиссиясе граждан хезмәте вазыйфасына карата тиешле квалификацион таләпләрдән һәм әлеге вазыйфа буенча вазыйфаи регламентның бүтән нигезләмәләреннән, шулай ук әлеге Нигезеләмә белән билгеләнгән нигезләмәләрдән һәм дәүләт граждан хезмәте турында Россия Федерациясе законнарыннан һәм Татарстан Республикасы законнарыннан чыгып эш итә.

4.4.9. Дәгъвачыларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын конкурс комиссиясе әгъзалары һәр конкурска атап кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге тарафыннан әзерләнә торган бәяләү битләрендә билгеләнә.

4.4.10. Конкурс башланыр алдыннан конкурс комиссиясе утырышында рәислек итүче конкурс комиссиясе әгъзаларына аны уздыру, бәяләр кую тәртибе, конкурс комиссиясе әгъзаларының хокуклары һәм бурычлары турында инструкция бирә.

4.4.11. Конкурс комиссиясенең һәр әгъзасы барлык конкурста катнашучылар өчен конкурс комиссиясе секретареннан бәяләү битләре ала һәм тиешле баллар куя.

һәр бәяләү битендә балларның гомуми санын куйганнан соң конкурс комиссиясе әгъзасы бәяләү битләренә имза сала һәм аларны конкурс комиссиясе секретарена тапшыра.

4.4.12. Бәяләү битләре нигезендә конкурс комиссиясе секретаре конкурста һәр катнашучы алган йомгаклау балларын куша.

Бәяләү битендә төзәтүләр рөхсәт ителми.

Кандидатларны бәяләүнең йомгак нәтиҗәләре анкетада (әлеге Нигезләмәгә 7 нче кушымта) кертелә.

4.5. Конкурсның икенче этабы нәтиҗәсе һәм бер үк вакытта йомгак нәтиҗәләре граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә кандидатларның конкурс комиссиясе тарафыннан әзерләнгән рейтингларыннан гыйбарәт була.

конкурска йомгак ясау һәм граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә кандидат турында карар кабул итү өчен түбәндәгеләр нигез була:

кандидатлар тарафыннан барлык конкурс процедураларын узу нәтиҗәләре буенча алынган бәяләү критерийлары буенча баллар суммалары;

кандидатлар белән әңгәмәләр йомгаклары буенча вазыйфасы үзенә караган структур бүлекчәләр җитәкчеләре фикере (Министрлык җитәкчелеге фикере).

Конкурс комиссиясе конкурста җиңүче турындагы карарны, шулай ук Министрлыкның кадрлар резервына тәкъдим ителгән кандидатлар исемлекләрен раслый.

4.6. Әгәр конкурс уздыру нәтиҗәсендә биләү өчен конкурс игълан ителгән граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы буенча барлык кирәкле таләпләргә җавап бирерлек кандидатлар булмаса, конкурс комиссиясе өстәмә конкурс сынаулары уздыру турында карар кабул итәргә һәм яңа конкурс уздыру турында тәкъдим кертергә хокуклы.

4.7. Министр яңа конкурс уздыру турында яисә вакантлы вазыйфа биләү өчен билгеләнә торган таләпләргә иң туры килүче һәм иң күп балл җыйган конкурста катнашучыны граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына билгеләп кую (кадрлар резервына кертү) турында карар кабул итә.

4.8. Ике яисә аннан да күбрәк конкурста катнашучы тигез балл җыйганда конкурс комиссиясе рәисе фикере хәлиткеч була.

4.9. Конкурс уздыру нәтиҗәләре буенча биш көн эчендә конкурс комиссиясе тарафыннан карар кабул ителә, ул беркетмә рәвешендә рәсмиләштерелә һәм аңа конкурс комиссиясендә рәислек итүче, конкурс комиссиясе секретаре һәм конкурс комиссиясе утырышында катнашкан әгъзалары имза сала.

4.10. Конкурс нәтиҗәләре буенча конкурста җиңүчене граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына билгеләп кую турында Министрлык боерыгы бастырып чыгарыла һәм аның белән хезмәт контракты төзелә.

Граждан хезмәткәрен (гражданны) - конкурста җиңүчене кадрлар резервына кертү Министрлык боерыгы белән рәсмиләштерелә, граждан хезмәткәренең шәхси эш кәгазьләренә һәм граждан хезмәткәренең хезмәт эшчәнлеген раслаучы бүтән документларга тиешле язма ясала.

Бу чакта вазыйфалар номенклатурасы нигезендә конкурста җиңүчене вазыйфасына билгеләп куюга тәкъдим иткәндә Министрга мәҗбүри рәвештә

конкурс комиссиясе карары һәм комиссия шундый карар кабул итү өчен нигез булган материаллар тапшырыла.

4.11. Кандидатны граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына билгеләп куюдан баш тартылган очракта, Министрлыкның кадрлар резервында тиешле вазыйфа тәкъдим ителергә мөмкин. Граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына дәгъвачы Россия Федерациясе законнары нигезендә конкурс комиссиясе карарына шикаять белдерергә хокуклы.

4.12. Конкурста катнашучы кандидатларга кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге конкурс тәмамланганнан соң җиде көн эчендә конкурс нәтиҗәләре турында язма рәвештә хәбәр ителә.

Конкурс нәтиҗәләре турындагы мәгълүмат ул тәмамланганнан соң җиде көн эчендә Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла.

4.13. Граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурста катнашуга кертелмәгән дәгъвачыларның һәм конкурста катнашучы кандидатларның документлары конкурс тәмамланганнан соң өч ел дәвамында аларның язма гаризасы нигезендә кире кайтарылырга мөмкин. Шушы срок узганчы документлар Министрлык архивында саклана, аннары алар юк ителергә тиеш.

4.14. Конкурста катнашуга бәйле чыгымнар (конкурс уздыру урынына бару һәм аннан кайту, торак яллау, яшәү өчен чыгымнар, элемтә чараларыннан файдалану һәм башкалар) кандидатларның үз акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

-----------------------------------------------------------------

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 17.02.2014 № К-26/03-03 боерыгы белән расланган Нигезләмәгә
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы юстиция министрына

______________________________
(инициаллары, фамилиясе)

**ГАРИЗА**

"__" _________ 201_ ел.

Дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс игълан итүегезне үтенәм
________________________________________________________________
(вазыйфа атамасы)
________________________________________________________________
(бүлек атамасы)

Әлеге вазыйфаны биләүгә дәгъвачыга түбәндәге таләпләр белдерелә:
________________________________________________________________
(таләпләрне санап чыгарга)

Кушымта: Вазыйфаи регламент күчермәсе.

______________________ ______________________ ______________________
(биләгән вазыйфа) (имзасы) (фамилиясе һәм инициаллары)

КИЛЕШТЕРЕЛДЕ
Татарстан Республикасы
юстиция министры урынбасары

______________________ ______________________
(имзасы, датасы) (фамилиясе һәм инициаллары)

Татарстан Республикасы
Юстиция министрлыгының
17.02.2014 № К-26/03-03
боерыгы белән расланган
Нигезләмәгә
2 нче кушымта

**КОНКУРСНОЙ КОМИССИЯСЕ БЕРКЕТМӘСЕ №_____**

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының конкурс комиссиясе утырышында биләнә торган вакантлы вазыйфага (кадрлар резервына кертүгә) конкурс сайлап алуы буенча тавыш бирү уздырылды

______________________________________________________________

(вазыйфа атамасы)

______________________________________________________________

(структур бүлекчә атамасы)

Конкурс комиссиясе әгъзаларыннан утырышта катнаштылар ______.

Тавыш бирү нәтиҗәләре:

1. ________________________________________ "яклап" ______, "каршы" _____.
(кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме)
2. ________________________________________ "яклап" ______, "каршы" _____.
(кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме)

……………………………………………

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча

______________________________________________________________

(кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Конкурс комиссиясе әгъзаларының иң күп тавышын җыйды, бу тавыш бирүдә катнашкан комиссия әгъзаларының ______ процентын тәшкил итә.

Конкурс
комиссиясе рәисе ____________ ______________________________
(имзасы) (фамилиясе һәм инициаллары)

Конкурс
комиссиясе рәисе урынбасары ____________ ______________________________
(имзасы) (фамилиясе һәм инициаллары)

Конкурс
комиссиясе секретаре ____________ ______________________________
(имзасы) (фамилиясе һәм инициаллары)

Конкурс
комиссиясе әгъзалары : ____________ ______________________________
(имзасы) (фамилиясе һәм инициаллары)

Конкур уздыру датасы "__" _____________ 201_ ел.

Татарстан Республикасы
Юстиция министрлыгының
17.02.2014 № К-26/03-03
боерыгы белән расланган
Нигезләмәгә
3 нче кушымта

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә)

# КАНДИДАТЛАРГА КАРАТА ТАЛӘПЛӘР

## I. Гомуми таләпләр

1.1. Конкурста катнашу хокукына 18 яшькә җиткән, Россия Федерациясе дәүләт телен белгән, федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актлары белән билгеләнгән, дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү (кадрлар резервына керү) өчен кирәкле булган таләпләргә туры килә торган Россия Федерациясе гражданнары ия була.

1.2. Граждан түбәндәге очракта конкурста катнашуга кертелми:

1) закон көченә кергән суд карары белән хокукка сәләтсез яисә хокукка сәләте чикләнгән дип танылган;

2) дәүләт хезмәте (граждан хезмәте) вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларын үтәү мөмкинлеген закон көченә кергән суд карары белән юкка чыгара торган җәзага хөкем ителгән, шулай ук федераль закон белән билгеләнгән тәртиптә хөкем ителеше юкка чыгарылмаган яисә алынмаган очракта;

3) дәүләт сере һәм федераль закон белән саклана торган бүтән серне тәшкил итүче белешмәләрне белү мөмкинлеген рәсмиләштерү процедурасын узудан баш тарткан, граждан биләүгә дәгъва кыла торган граждан хезмәте вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларын үтәү мондый белешмәләрне куллануга бәйле булса;

4) медицина оешмасы бәяләмәсе белән расланган граждан хезмәтенә керү өчен каршылык сыйфатындагы авыруы булган.;

5) граждан хезмәткәренең якын туганы яисә туган-тумачасы булган (ата-анасы, ире яисә хатыны, балалары, абый-энеләре, апа-сеңелләре шулай ук ир яисә хатынының абый-энеләре, апа-сеңелләре, ата-анасы, ир яисә хатынының балалары һәм балаларының ирләре яисә хатыннары), граждан хезмәте вазыйфасын биләү берсенең икенчесенә турыдан-туры буйсынуында яисә контролендә булуга бәйле булса;

6) Россия Федерациясе гражданлыгыннан чыккан яисә башка дәүләт гражданлыгын алгын;

7) Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә бүтәне каралмаган булса, башка

дәүләт гражданлыгы булган;

8) граждан хезмәтенә кергәндә ялган документлар яисә күрәләтә ялган белешмәләр биргән;

9) граждан хезмәтенә кергәндә "Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында" 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законы белән билгеләнгән белешмәләрне бирмәгән яисә керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында күрәләтә ялган белешмәләр биргән;

10) законлы нигезе булмый торып, чакырылыш комиссиясе бәяләмәсе нигезендә чакырылыш буенча хәрби хезмәт узмаган дип танылган (контракт буенча хәрби хезмәт узган гражданнардан тыш).

## II. Квалификация таләпләре

2.1. Белеменә һәм дәүләт хезмәте стажына яисә эш стажына (тәҗрибәсенә) карата квалификация таләпләре:

дәүләт хезмәтенең баш вазыйфалары – югары һөнәри белеме, әйдәүче яисә өлкән дәүләт вазыйфаларында кимендә ике ел дәүләт хезмәте стажы яисә белгечлеге буенча кимендә өч ел эш стажы булу;

дәүләт хезмәтенең әйдәүче вазыйфалары – югары һөнәри белеме, өлкән яисә кече дәүләт вазыйфаларында кимендә бер ел дәүләт хезмәте стажы яисә белгечлеге буенча кимендә ике ел эш стажы булу;

"белгечләр" категориясе дәүләт хезмәтенең өлкән вазыйфалары – стажына таләпләр беледермичә генә, югары һөнәри белеме булу;

"тәэмин итүче белгечләр" категориясе дәүләт хезмәтенең өлкән вазыйфалары – стажына таләпләр беледермичә генә, эшчәнлеге юнәлеше буенча урта һөнәри белеме булу;

дәүләт хезмәтенең кече вазыйфалары – стажына таләпләр беледермичә генә, эшчәнлеге юнәлеше буенча урта һөнәри белеме булу.

2.2. Вазыйфаи бурычларны башкару өчен кирәкле һөнәри белемнәренә һәм күнекмәләренә карата квалификация таләпләре дәүләт хезмәткәренең вазыйфаи регламенты һәм "Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи бурычларын башкару өчен кирәкле һөнәри белемнәренә һәм күнекмәләренә карата квалификация таләпләре турында" Татарстан Республикасы юстиция министрының 2006 елның 17 августындагы № К-119/03-02 боерыгы белән билгеләнә.

------------------------------------------------------

Татарстан Республикасы
Юстиция министрлыгының
17.02.2014 № К-26/03-03
боерыгы белән расланган
Нигезләмәгә
4 нче кушымта

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә (кадрлар резервына керүгә) кандидатлар тарафыннан тапшырыла торган документлар һәм материаллар
ИСЕМЛЕГЕ

1. Конкурста катнашуга теләк белдергән Россия Федерациясе гражданы Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына түбәндәгеләрне тапшыра:

а) шәхси гаризасын (әлеге Исемлеккә кушымта);

б) үз кулы белән тутырган һәм имзаланган анкетасын, аның формасы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 26.05.2005 № 667-р күрсәтмәсе белән расланган, фотографияләрен;

в) паспортының яисә аны алыштыручы документның күчермәсен (тиешле документ конкурска килүгә шәхсән тапшырыла);

г) кирәкле һөнәри белемен, эш стажын һәм квалификациясен раслаучы документлар:

хезмәт кенәгәсенең күчермәсе (хезмәт эшчәнлеге беренче мәртәбә башкарыла торган очраклардан гайре) яисә гражданның хезмәт эшчәнлеген раслаучы бүтән документлар;

һөнәри белеме турындагы документларның күчермәләре, шулай ук граждан теләге буенча – өстәмә һөнәри белеме турында, гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем бирелү турында, алар нотариаль яисә эш (хезмәт) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган булырга тиеш;

д) граждан хезмәтенә керергә яисә аны узарга каршы килерлек авыруы булмавы турында документ, аның формасы Россия Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 14.12.2009 № 984н боерыгы белән расланган;

е) "Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында" 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль закон, башка федераль законнар, Россия Федерациясе Президенты указлары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары белән каралган бүтән документлар.

2. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында вазыйфа биләүче, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына керүгә) конкурста катнашырга теләк белдергән граждан хезмәткәре Министр исеменә гариза яза.

Бүтән дәүләт органында вазыйфа биләүче, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына керүгә) конкурста катнашуга теләк белдергән граждан хезмәткәре

Министрлыкка Министр исеменә  исеменә гариза яза һәм үз кулы белән тутырган һәм имзаланган, гражданхезмәткәре хезмәт итә торган дәүләт органының кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган анкетасын, фотографияләрен тапшыра.

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) кандидатлар тарафыннан тапшырыла торган документлар һәм материаллар исемлегенә кушымта

Татарстан Республикасы юстиция министрына

_______________________________________
(инициаллары, фамилиясе)

_______________________________________
(фамилиясе)

_______________________________________
(исеме, атасының исеме)

_______________________________________
_______________________________________яшим.
Тел. __________________________________
(эш, мобиль, E-mail)

## Гариза

Мине Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләү өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурста катнашуга кертүегезне сорыйм:_______________________________________________
(вазыйфа атамасы)

_______________________________________________________________
(бүлек атамасы)

"Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында" 2004 елны 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль закон, "Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында" 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, "Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында" Россия Федерациясе Президентының 01.02.2005 № 112 Указы, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турындагы нигезләмә, шул исәптән вакантлы вазыйфага карата белдерелә торган квалификацион таләпләр белән таныштым.

Конкурс уздыру датасы һәм урыны турында E-mail аша яисә шушы мобиль телефон номерына СМС-хәбәр җибәреп хәбәр итү белән килешәм.

Гаризага кушып бирәм:

_______________________________________________________________
(кушып бирелә торган документлапны күрсәтергә)

| | | |
|---|---|---|
| ______________ | ______________ | __________________________ |
| (дата) | (имза) | (имзаны расшифровкалау) |

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 17.02.2014 № К-26/03-03 боерыгы белән расланган Нигезләмәгә 5 нче кушымта

# КОНКУРСТА КАТНАШУЧЫЛАРНЫ БӘЯЛӘҮ КРИТЕРИЙЛАРЫ

## I. Дәүләт хезмәте культурасына туры килү

1.1. Һөнәри мотивация

Дәүләт хезмәтендә һөнәри яктан үз-үзеңне күрсәтүгә омтылыш, дәүләт идарәсе өлкәсендә хезмәттәге үсүгә ориентация.

1.2. Граждан позициясе

Эшчәнлегендә җәмгыятькә һәм дәүләткә хезмәт итү принципларын үтәү, законлылыкны, хезмәт этикасы кагыйдәләрен үтәү.

1.3. Һөнәри позициянең активлыгы

Куелган бурычларны хәл иткәндә инициатива күрсәтергә омтылу; мөмкин булган иң яхшы нәтиҗәгә ирешү өчен барлык көчен куярга әзер булу; физик һәм эмоциональ йөкләнешләр вакытында нәтиҗәле эш итү сәләте (стрессларга чыдамлылык).

1.4. Үзлегеннән үсешкә омтылыш

Үз белемнәрен, гыйлемнәрен һәм күнекмәләрен даими рәвештә камилләштерүгә омтылыш, дөньяга карашын киңәйтү, катнаш һөнәри өлкәләрдә белемнәр һәм тәҗрибә туплау.

## II. Дәүләт хезмәткәренең һөнәри компетентлыгы

2.1. Белем дәрәҗәсе

Төп һәм өстәмә һөнәри белеменең дәрәҗәсе, профиле һәм сыйфаты.

2.2. Һөнәри тәҗрибәсе

Тиешле һөнәри өлкәдәге эшчәнлегенең дәвамлылыгы һәм үзенчәлекләре; һөнәри эшчәнлегендә конкрет нәтиҗәләргә ирешүе; карьера үзенчәлекләре.

2.3. Махсус һөнәри белемнәре, гыйлемнәре һәм күнекмәләре

Тиешле өлкәдә һөнәри белемнәренең функциональ бурычларын нәтиҗәле башкарырлык дәрәҗәсе; Россия Федерациясенең һөнәри эшчәнлекне регламентлый торган законнары; хәзерге заман һөнәри технологияләре белән эшли белү.

2.4. Гомуми инструменталь күнекмәләр

Һөнәри эшчәнлекнең гомуми нәтиҗәлелеген арттыра торган күнекмәләрне белү дәрәҗәсе (компьютерны белү, гомуми грамоталык, чит телләр белү һәм башкалар).

III. Граждан хезмәткәренең шәхси-эшлекле сыйфатлары

3.1. Аналитик үзенчәлекләр

Фикер йөртүенең катлаулы мәсьәләләрне хәл итәргә ярдәм итә, мәгълүматны анализлауны һәм структуралаштыруны таләп итә торган системалылыгы һәм сыгылмалылык дәрәҗәсе; яңа, стандарт булмаган хәл ителешләрне табу сәләте.

3.2. Нәтиҗәле коммуникацияләр күнекмәләре

Эшлекле аралашу этикасын үтәү; аргументлы рәвештә үз фикерен яклый һәм оппонентларны ышандыра белү; эшлекле сөйләшүләр алып бару күнекмәләре булу.

3.3. Җаваплылык

Карарлар кабул иткәндә нигезле һәм мөстәкыйль булу; нәтиҗәгә ирешкәндә үзенә йөкләмәләр алуга әзер тору.

3.4. Оештыру сәләте

Үз эшчәнлеген һәм буйсынучылары эшчәнлеген нәтиҗәле планлаштыру, функцияләрне, вәкаләтләрне һәм җаваплылыкны бүлә белү бәрабәренә нәтиҗәләргә ирешү сәләте.

---------------------------------------------------------

Татарстан Республикасы
Юстиция министрлыгының
17.02.2014 № К-26/03-03
боерыгы белән расланган
Нигезләмәгә
6 нчы кушымта

______________________________
(инициаллары һәм фамилиясе)

Адресы:____________________
______________________________

Хөрмәтле ________________________!
(исеме, атасының исеме)

Сезнең:
(кирәклесен сайлап алырга)

а) граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына карата квалификацион таләпләренә туры килмәвегезгә;

б) граждан хезмәтенә керү һәм аны узу өчен дәүләт граждан хезмәте турындагы Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән чикләүләргә;

в) документларны вакытында тапшырмавыгызга (аларны тулы күләмдә яисә мәгълүмат сәбәпсез аларны рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыруыгызга);

г) тикшерү барышында федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актлары нигезендә гражданның дәүләт граждан хезмәтенә керүенә каршы килерлек хәлләр ачыклануга бәйле рәвештә дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының кадрлар резервына керүгә) конкурста катнашуга кертелмәвегез турында хәбәр итәм ________________________________________
________________________________________________________________________
(вазыйфа, бүлек атамасы)

Документлар язма гариза нигезендә түбәндәге адрес буенча кире кайтарылырга мөмкин: 420503, Казан шәһәре, Кремль ур., 16, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы, Кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге, 103 нче кабинет, телефон: 292-51-48.

Кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге башлыгы

____________________ ____________________________________
(имзасы) (фамилиясе һәм инициаллары)

Татарстан Республикасы
Юстиция министрлыгының
17.02.2014 № К-26/03-03
боерыгы белән расланган
Нигезләмәгә
7 нче кушымта

Вакантлы вазыйфа биләү өчен
кандидатның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү
**АНКЕТАСЫ**

__________________________________________
(вакантлы вазыйфа атамасы)

______________________________________________
(кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме)

| № т/с | Кандидатның сыйфатларын бәяләү күрсәткечләре | Кандидат квалификациясенең белдерелә торган таләпләргә туры килү дәрәҗәсе | | |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Һөнәри белем дәрәҗәсе | туры килә | билгеле бер әзерлек узгач, туры киләчәк | туры килми |
| | Структур бүлекчә вәкиле | | | |
| | Кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге вәкиле | | | |
| | Бәйсез эксперт | | | |
| | Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты вәкиле | | | |
| 2 | Яңадан һөнәри әзерлек узу һәм квалификациясен арттыру | туры килә | | туры килми |
| | Кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге вәкиле | | | |
| | Бәйсез эксперт | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты вәкиле | | | |
| 3 | Белгечлек буенча эш стажы һәм эш тәҗрибәсе | туры килә | | туры килми |
| | Структур бүлекчә вәкиле | | | |
| | Кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге вәкиле | | | |
| | Бәйсез эксперт | | | |
| | Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты вәкиле | | | |
| 4 | РФ Конституциясен һәм ТР Конституциясен, федераль законнарны һәм ТР законнарын, эшчәнлек юнәлеше буенча таяну документларын белү дәрәҗәсе | туры килә | билгеле бер әзерлек узгач, туры киләчәк | туры килми |
| | Структур бүлекчә вәкиле | | | |
| | Кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге вәкиле | | | |
| | Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының бердәм банкы бүлеге вәкиле | | | |
| | Бәйсез эксперт | | | |
| | Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты вәкиле | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 5 | Һөнәри эшлекле һәм шәхси сыйфатлары дәрәҗәсе | туры килә | билгеле бер әзерлек узгач, туры киләчәк | туры килми |
| | Структур бүлекчә вәкиле | | | |
| | Кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге вәкиле | | | |
| | Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының бердәм банкы бүлеге вәкиле | | | |
| | Бәйсез эксперт | | | |
| | Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты вәкиле | | | |
| 6. | Биләгән вазыйфасында эш нәтиҗәләре | биләгән вазыйфасына туры килә | эшендә җитешсезлекләр бар | биләгән вазыйфасына туры килми |
| | Структур бүлекчә вәкиле | | | |
| | Кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге вәкиле | | | |
| | Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының бердәм банкы бүлеге вәкиле | | | |
| | Бәйсез эксперт | | | |
| | Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты вәкиле | | | |
| 7 | Биләүгә планлаштырыла торган вазыйфа буенча | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | эшне белүе | | | |
| | Структур бүлекчә вәкиле | | | |
| | Бәйсез эксперт | | | |
| | Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты вәкиле | | | |
| 8 | Хәтере (истә калдыру төре, тизлеге, исендә тоту вакыты) | туры килә | билгеле бер әзерлек узгач, туры киләчәк | туры килми |
| | Структур бүлекчә вәкиле | | | |
| | Кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге вәкиле | | | |
| | Бәйсез эксперт | | | |
| | Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты вәкиле | | | |
| 9 | Игътибарлылык күләме һәм тотрыклылыгы | туры килә | билгеле бер әзерлек узгач, туры киләчәк | туры килми |
| | Структур бүлекчә вәкиле | | | |
| | Кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге вәкиле | | | |
| | Бәйсез эксперт | | | |
| | Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты вәкиле | | | |
| 10 | Шәхси сыйфатлары (үз-үзенә бәя бирү сәләте, | туры килә | билгеле бер әзерлек узгач, | туры килми |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | психологик тотанаклык) | | туры киләчәк | |
| | Структур бүлекчә вәкиле | | | |
| | Кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге вәкиле | | | |
| | Бәйсез эксперт | | | |
| | Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты вәкиле | | | |
| 11 | Сөйләм культурасы, сөйләшү манерасы, тышкы кыяфәте | туры килә | билгеле бер әзерлек узгач, туры киләчәк | туры килми |
| | Структур бүлекчә вәкиле | | | |
| | Кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге вәкиле | | | |
| | Бәйсез эксперт | | | |
| | Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты вәкиле | | | |
| 12 | Үз фикерләрен язмача һәм телдән бәян итү сәләте | | | |
| | Структур бүлекчә вәкиле | | | |
| | Кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге вәкиле | | | |
| | Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының бердәм банкы бүлеге вәкиле | | | |
| | Бәйсез эксперт | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты вәкиле | | | |
| 13 | Кандидатка гомуми бәя | вакантлы вазыйфага туры килә | билгеле бер әзерлек узгач, вакантлы вазыйфага туры киләчәк | вакантлы вазыйфага туры килми |
| | Структур бүлекчә вәкиле | | | |
| | Кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге вәкиле | | | |
| | Бәйсез эксперт | | | |
| | Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты вәкиле | | | |
| | Нәтиҗә | вакантлы вазыйфага билгеләргә тәкъдим итәргә | Предложить кандидату должность в кадровом резерве Министерства | Отказать в приеме на гражданскую службу на вакантную должность |
| | Җитәкче урынбасары | | | |
| | Структур бүлекчә вәкиле | | | |
| | Кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге вәкиле | | | |
| | Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының бердәм банкы бүлеге вәкиле | | | |
| | Бәйсез эксперт | | | |

Йомгак:

Конкурс комиссиясе рәисе _________ _______________________
(имзасы) (фамилиясе һәм инициаллары)

Конкурс комиссиясе секретаре ___________ _________________________
(имзасы) (фамилиясе һәм инициаллары)